ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
26.05.2023

г. Иннополис

КАРАР
60

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы №89 карары белән расланган җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2017 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, шулай ук норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы №89 карары белән расланган җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.10. бүлекнең аталышын үзгәртеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар һәм оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге».

1.2. 3. бүлекнең аталышын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ

процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлек гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантларын, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтергә тиеш».

2. Әлеге карар http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә, шулай ук http://verhniy-uslon.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш .

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче И.Р. Хуззәтов